ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ТУКТАРОВО-УРДАЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ТИМӘШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2018 елның 2 октябре № 11

Туктар-Урдаласы авыл җирлеге Туктар-Урдаласы авылы территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьялары, Тимәшавыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар КАРАР БИРДЕ:

1. 2018 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлеге Туктар-Урдаласы авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. «2019 елда Туктар-Урдаласы авылында 18 яшькә җиткән һәр гражданнан 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан файдалану белән килешәсезме соравы буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

-Туктар Урдаласы торак пунктының Совет, Вахитов урамнары буенча су линиясен өлешчә алыштыру.

« Әйе Юк».

3. Әлеге карарны Туктар-Урдаласы авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Туктар-Урдаласы авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге
башлыгы М.М.Җиһаншин